**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________ ПР-171 25.08.2025 № ___

**“Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларының яшь белгечләренә – педагогик хезмәткәрләренә акча билгеләү һәм түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2024 елның 13 августындагы ПР-146 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 47 статьясының 10 пункты нигезендә, Актаныш муниципаль берәмлегенең муниципаль белем бирү оешмаларына яшь белгечләрне җәлеп итү һәм аларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 1.2 пунктына, тәкъдимнәр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

- "Урта һөнәри белем бирү студентлары өчен Мәгариф министрлыгының “Урта һөнәри белем бирү программалары буенча укучы балигъ булган затларга мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә рөхсәт бирү тәртибен раслау турында” 2023 елның 16 октябрендәге 771 номерлы боерыгы нигезендә, уку чоры турында ул белем ала торган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан мөстәкыйль билгеләнгән үрнәк буенча белешмә бирергә";
- "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2020 елның 08 июнендәге 165-ФЗ номерлы (соңгы редакция) Федераль законның 46 һәм 108 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә югары белем бирү программалары буенча белем алучы студентларны эшкә кабул итү өчен уку чоры турында мөстәкыйль билгеләнгән үрнәк буенча белешмә бирергә".

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев